| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«НОВОИШТЕРЯКСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ЯҢА ИШТИРӘК<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2018 елның 15 октябре** **№ 24**

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 25 октябрендәге 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясен куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы карар бирде:

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»2015 елның 25 октябрендәге 8 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 пунктның 2 пунктындагы беренче абзацында «фатирлар» сүзләреннән соң «фатирлар өлешләре» сүзләре белән тулыландырырга;

2 пунктның 3 пунктчасының беренче абзацыннан соң «торак йортлар» сүзләрен «торак йортлар өлешләре»сүзләре белән тулыландырырга;

2 пунктның 3 пунктчасының 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«составына бер генә торак йорт керә торган бердәм күчемсез комплекслар;».

2. Әлеге карарны Яңа Иштирәк авыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Лениногорск муниципаль

районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2017 елның 1 гыйнварыннан физик затлар милкенә салым исәпләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Яңа Иштирәк авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге
башлыгы, авыл
Советы рәисе Г.Р.Мәүлетова